МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.12.2019 Казан ш. № 02-139

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 27.09.2018 ел, № 02-110 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджеты классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 27.09.2018 ел, № 02-110 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджеты классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләргә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 27.12.2018 ел, № 02-152, 15.03.2019 ел, № 02-31, 17.10.2019 ел, № 02-108, 04.12.2019 ел, № 02-129 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
24 декабрь, 2019 ел,
№ 02-139 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 27.09.2018 ел, № 02-110 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджеты классификациясен куллану тәртибен билгеләү, анықлау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләргә кертелә торган үзгәрешләр

1. «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты чыгымнары исемлеге һәм аларны тиешле максатчан статьяларга кертү кагыйдәләре» 2 пунктында:

а) «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасы икътисади үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасы» 2.11. пунктчасында «11 8 01 00000 «Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын булдыру» максатчан статьясында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның түбәндәге юнәлешләре буенча төп чараны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:»;

түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 60680 «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисади зона» индустриаль паркы («Алабуга-2» индустриаль паркы) инфраструктурасы объектларын булдыру, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләүнең барышына средстволарны максатчан тоту максатыннан чыгып, төзелеш күзәтчелеге»;

б) «2013 – 2022 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы» 2.14. пунктчасында «14 6 06 00000 «Агосәнәгать комплексы объектларын төзү һәм модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарны компенсацияләү» төп чарасы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- R4720 Агросәнәгать комплексы объектларын булдыруга һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча агросәнәгать комплексы объектларын булдыруга һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Агросәнәгать комплексы объектларын булдыруга һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга бюджетларга тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45472 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле коды буенча чагылдырыла.»;

в) түбәндәге эчтәлектәге $2.30^3$. пунктчасын өстәргә:

«$2.30^3$. «2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ тутыру компрессор станцияләрен төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы

«2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ тутыру компрессор станцияләрен төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының максатчан статьялары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

36 0 00 00000 «Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ тутыру компрессор станцияләрен төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы

Әлеге максатчан статья буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.12.2012 ел, № 1199 карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт программалары исемлеге нигезендә эшләнгән «2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ тутыру компрессор станцияләрен төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыруга түбәндәге төп чара буенча хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

36 0 01 00000 «Автомобильләргә яңа газ тутыру компрессор станцияләрен төзү һәм аларны файдалануга тапшыру» төп чарасы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның түбәндәге юнәлеше буенча төп чараны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

- 5682F Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, транспорт чараларына табигый газ ягулыгы тутыру объектларын төзүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен компенсацияләүгә субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча транспорт чараларына табигый газ ягулыгы тутыру объектларын төзүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен компенсацияләүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына бюджетларга тапшырыла торган бюджетара транфертлар» 000 2 02 49001 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

г) «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Россия Федерациясе дәүләт бюджеттан тыш фондлары чыгымнарының программага кертелмәгән юнәлешләре» 2.31. пунктчасында: «99 0 00 00000 «Чыгымнарның программага кертелмәгән юнәлешләре» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешләрен өстәргә:

«- 5473F Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә китерелгән зыянны компенсацияләү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә китерелгән зыянны компенсацияләүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә китерелгән зыянны компенсацияләүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45473 02 0000 150 коды буенча чагылдырыла.»;

«- 55500 Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге күрсәткечләренә ирешүгә федераль бюджет средстволары хисабына чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге күрсәткечләренә ирешүгә федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге күрсәткечләренә ирешүгә бюджетларга тапшырыла торган бюджетара транфертлар» 000 2 02 45550 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

«- 67100 Тәгәлләнмәгән төзелеш объектларын – күп фатирларны йортларны төзүне тәгәлләүне финанслау буенча чараларны тормышка ашыру максатыннан чыгып, «Өлешкә кереп төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы мөлкәти кертеме

- 67110 Устав эшчәнлеген хәл кылу максатыннан чыгып, «Өлешкә кереп төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» унитар коммерциясез оешмасына Татарстан Республикасы мөлкәти кертеме.

2. 2 нче кушымтада:

а) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «11 8 01 00000 | «Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын булдыру» төп чарасы |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «11 8 01 60680 | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисади зона» индустриаль паркы («Алабуга-2» индустриаль паркы) инфраструктурасы объектларын булдыру, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләүнең барышына средстволарны максатчан тоту максатыннан чыгып, төзелеш күзәтчелеге»; |

б) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «14 6 06 65470 | Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә модульле теплицалар сатып алуга бәйле чыгымнарын компенсацияләүгә субсидияләр» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «14 6 06 R4720 | Агросәнәгать комплексы объектларын булдыруга һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга финанслашыла торган чыгымнар»; |

в) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «35 0 F2 55550 | Заманча шәһәр мохитен булдыру программаларын тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «36 0 00 00000 | «Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ тутыру компрессор станцияләрен төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы |
| 36 0 01 00000 | «Автомобильләргә яңа газ тутыру компрессор станцияләрен төзү һәм аларны файдалануга тапшыру» төп чарасы |
| 36 0 01 5682F | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, транспорт чараларына табигый газ ягулыгы тутыру объектларын төзүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен компенсацияләүгә субсидияләр»; |

г) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «99 0 00 54690 | Федераль бюджет средстволары хисабына, 2020 елда Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «99 0 00 5473F | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә китерелгән зыянны компенсацияләү»; |

д) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «99 0 00 54850 | Федераль бюджет средстволары хисабына, хәрби хезмәттән (хезмәттән) киткән гражданнарны һәм аларга тигезләштерелгән гражданнарны торак белән тәэмин итү» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «99 0 00 55500 | Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге күрсәткечләренә ирешүгә федераль бюджет средстволары хисабына чыгымнар»; |

е) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «99 0 00 60450 | Авыл хуҗалыгы өлкәсендә башка чаралар» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «99 0 00 67100 | Төгәлләнмәгән төзелеш объектларын – күп фатирларны йортларны төзүне төгәлләүне финанслау буенча чараларны тормышка ашыру максатыннан чыгып, «Өлешкә кереп төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы мөлкәти кертеме |
| 99 0 00 67110 | Устав эшчәнлеген хәл кылу максатыннан чыгып, «Өлешкә кереп төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» унитар коммерциясез оешмасына Татарстан Республикасы мөлкәти кертеме». |